| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ГОРОДА БУИНСКА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БУА<br>ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«03» апрель 2023 ел № 30

Буа шәһәре

Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районы Буа шәһәре муниципаль
берәмлегендә гражданнарның үзара салым
акчаларын җыю тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизацияләү турында» Указы, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Буа шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы белән Буа шәһәре җирле референдумында (гражданнар җыенында) 2022 елның 25 ноябрендәге 2 номерлы карары белән кабул ителгән карарларны гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Буа шәһәре Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 22 ноябрендәге 62 номерлы «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Буа шәһәре муниципаль берәмлектә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Буа шәһәрендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Тәртипнең 2 пунктына киләсе редакциядә 2 абзацны өстәргә:

«Үзара салым акчаларын түләүдән азат итергә:

- Россия Федерациясендә өлешчә мобилизацияләү кысаларында мобилизацияләнгән гражданнарны, шулай ук мобилизацияләнгән белән бергә яки аннан аерым яшәүче гаилә әгъзаларын;

- Украинада махсус хәрби операция зонасында контракт буенча хәрби хезмәт узучы хәрбиләрне, шулай ук мобилизацияләнгән белән бергә яки аннан аерым яшәүче гаилә әгъзаларын;

- Украинадагы махсус хәрби операция зонасындагы ирекleләрне, шулай ук мобилизацияләнгән белән бергә яки аннан аерым яшәүче гаилә әгъзаларын.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга ( http://pravo.tatarstan.ru/ Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында), шулай ук Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адрес буенча урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы, Буа районы, Буа шәһәре, Космовский ур., 91Б йорт адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Буа шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Т.Н. Кирилина